СОВЕТ ШИШИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ 24.06.2025

КАРАР № 134

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 нче ноябре 517 номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге советының 15.11.2010 №10 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитеты турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 3.2.27 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.27. Балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;».

1.2. 5.6 пунктының 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе гражданлыгын яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләтнең гражданлыгы (подданствосы) йә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документ яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданы, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкача каралмаган булса;».

2. Әлеге карарны интернетта - "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы" ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Салихҗанов